ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.04.2023 Баулы шәһәре №105

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир участогын яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 141 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир участогын яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 141 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2 бүлегендә:

2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ

номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы экспертлар тарафыннан күрсәтелә;»;

3 нче бүлегендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре. Күрсәтелгән хезмәтләрне гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә бирү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар алган муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да»;

түбәндәге эчтәлекле 3.9. пункт өстәргә:

«3.9. Муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе

Муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү каралмаган.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров